

Телəк һəм бердəмлек булганда сvнеп бара торган авылга да жан орергə була икəн. Бу авыл мине халкы, табигате, саф һавасы белəн жəлеп итте. Биредə заманында авыл горлəп яшəгəн, хəтта сыер котvлəре дə булган.
Шулай, авылларынын гомерен озайтып торучылар турында, ягъни Темниковский районындагы Енаково-Янак татар авылы һəм халкы турында сvзебез. Əлеге авыл шул районнын Аксёль авыл жирлегенə керə. Шуструй елгасында урнашкан. “Пенза губернасы торак урыннары исемлеге” ндə (1869) Енаково Краснослободск оязенен 19 йортлы казна авылы дип язылган. Бvген əлеге авылда мəчете белəн утыз оч йорт бар һəм биредə барлыгы 6-7 йортта унлап кеше кыш чыгарга кала.



Авылнын атамасы Россия Дəvлəтенен Коньяк-кончыгыш чигендəге Темников засечная сызыгындагы йомышлы кешелəр Енакеевлар торак пунктнын хужалары булган. Мамлей - Алтын Урдадан Россиягə хезмəткə кvчкəн морзанын исеме. Мамлей морзасынын улы Енак vз вакытында Темников морзаларынын гаскəр башлыкларынын берсе дип сакналган, хəзерге Темников районында гына тvгел, ə Касыйм һəм Выкса тирəсендə дə зур жир билəмəлəре булган. Ул Енаково авылына нигез салган дип язылган кvп кенə тарихи чыганакларда. Енак морза Мамлеевныкы булган жирлəр 1627 елда анын дvрт улы - Сюнгали, Сюмбай, Ембай һəм Аюкай морзалары арасында бvленə. Алга таба Мамлеевлар нəселе бик тиз vсə, утарлары бvленə һəм кечерəя. Шуна кvрə алар Мамлеев морзасы Енактан мирас итеп алынган билəмəлəргə, ваклап сатылган билəмəлəргə остəп, патшадан остəмə жирлəр алганнар. Бvген шушы морзалар нигезен югалтмыйча (əлеге авылда кvбесе Мамлеев фамилиясен йортə) авыл очен яшилəр һəм тырышып эшлилəр. Шулай, 2 августта авыл урамы чокырларын олешчə vз кочлəре белəн ремонтлаганнар, ə агачлардан арыну субботнигы 17 августта оештырганнар. Əлеге чараны топ оештыручыга, Руслан Булгаковка аерым рəхмəтне юллыйлар. Тагы активларны да əйтеп китəсем килə: ул – Марат Авзал улы Мамлеев, Ильнур Равил улы Кугушев һəм башкалар. Тумышы белəн Янак авылыннан, бvген Санкт-Петербургта гомер итvче, татарча китап укучылар онлайн марафонында жинvче дипломы белəн бvлəклəнгəн Исмагыйль Ибраһим улы Мамлеев саф татарча, vзебезчə ВК сайтларында болай дип яза: “Бик зур рəхмəт барыгызга, кадерле авылдашларым.” Əйтеп китəргə кирəк, əлеге авылда туып vскəннəрне язмыш Питер, Мəскəv якларында яшəтсə дə, рухи, матди ярдəмнəрен авыл кирəк-яракларына жибəреп торалар. Кендек каны тамган якларын онытмыйлар. Шулай, сvнеп килгəн авылларын яшəтv очен Самообложение программасына да керергə акча жыялар. Əлеге чарада актив Авзаль Фатих улы Мамлеев, Нюрия Шекюр кызы Мамлеева, Ряшидə Алим кызы Мамлеева. Тырыш кешелəрнен эшлəре ун булсын! Шулай булгач, Янак авылынын килəчəге ометле.
Енаково авылынын сайтын алып барган Гульнара Наиль кызы Кугушевага рəхмəтемне

**белдерәм.**
**Наилә НАСЫРОВА**